СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 Әгерҗе шәһәре № 12-10

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендәге 10-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иҗтимагый Советының 2021 елның 11 ноябрендәге хатын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендәге 10-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районыныц рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, шулай ук “Татмедиа” АҖ филиалы “Әгерҗе хәбәрләре” Әгерҗе районы газетасы вакытлы матбугат басмасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
«19» 11 2021 ел, № 12-10
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендәге 10-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр**

1) **1 «ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР» өлешендә:**

- 1.4 пунктта «ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларында» сүзләреннән соң «законлылык» сүзен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген Иҗтимагый совет Регламенты нигезендә оештыра, ул Иҗтимагый совет Президиумы тарафыннан раслана.».

2) **4 «ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫ ФОРМАЛАШТЫРУ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ ВАКЫТЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ» өлешендә:**

- 4.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет, әгәр аның составына әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән Совет әгъзалары санынннан кимендә өч чирек өлеше керсә, оешкан дип санала».

3) **5 «ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ӘГЪЗАСЫНЫҢ СТАТУСЫ, ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ» өлешендә:**

- 5.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Иҗтимагый Совет әгъзасы үз статусын раслаучы документ булган Совет әгъзасы таныклыгына ия. Иҗтимагый Совет әгъзасы үз вәкаләтләре чоры дәвамында таныклыктан файдалана. Иҗтимагый совет рәисе һәм Иҗтимагый совет Президиумы әгъзалары таныклыкларына Әгерҗе муниципаль районы башлыгы имза сала. Советның башка әгъзаларының таныклыклары Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан имзалана. Таныклык үрнәге һәм тасвирламасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы күрсәтмәсе белән раслана».

4) **6 «ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ЭШЧӘНЛЕГЕН ОЕШТЫРУ» өлешендә:**

- 6.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Иҗтимагый Совет карарлары аның утырышта катнашучы әгъзаларының карарлары, бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр рәвешендә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм рекомендация характерында була. Иҗтимагый Советның оештыру һәм аның эшчәнлегенең башка мәсьәләләре буенча карарлары Иҗтимагый Совет әгъзалары өчен мәҗбүри характерга ия һәм, әгәр әлеге Нигезләмәдә башкасы каралмаган булса, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Иҗтимагый совет рәисе тавышны хәлиткеч булып тора.»;

- 6.4 пунктында:

«Иҗтимагый Совет карарлары рекомендация характерында була» сүзләрен төшереп калдырырга.»;

- «һәм Иҗтимагый советка нигезләнгән җаваплар» сүзләреннән соң «30 календарь көн» санын «15 календарь көн» санына алмаштырырга»;

- 6.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Иҗтимагый советта нәтиҗәле эш оештыру максатыннан даими комиссияләр төзелә. Даими комиссияләрне формалаштыру һәм эшләү тәртибе Иҗтимагый совет Регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла. Иҗтимагый совет агымдагы мәсьәләләрне оператив карау өчен вакытлы комиссияләр һәм эшче төркемнәр төзергә хокуклы.

Иҗтимагый советта Иҗтимагый совет президиумы даими эшли, аның составына Иҗтимагый советының рәис урынбасары, секретаре һәм даими комиссияләре җитәкчеләре керә.

Иҗтимагый советның даими комиссияләре составына бары тик Иҗтимагый совет әгъзалары гына керә. Эш төркемнәре составына Иҗтимагый совет әгъзаларыннан тыш иҗтимагый берләшмәләр рәисләре һәм Иҗтимагый совет эшенә җәлеп ителгән башка гражданнар керергә мөмкин.»;

- 6.5 пуктында:

«Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла» сүзләреннән соң «Иҗтимагый совет президиумы тарафыннан расланган Иҗтимагый совет Регламенты нигезендә» сүзләрен остәргә;

- 6.10 пуктында:

«Иҗтимагый совет Рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Иҗтимагый совет Рәисе карары буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының берсе башкара.» сүзләрен «Иҗтимагый совет Рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Иҗтимагый совет Рәисе урынбасары башкара. Иҗтимагый совет әгъзалары үзләренең составыннан Иҗтимагый совет Рәисе урынбасарын күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән сайлап алалар. Иҗтимагый совет Рәисе урынбасары Иҗтимагый совет Рәисе булмаганда Иҗтимагый совет Рәисе вазыйфаларын башкара.» сүзләренә алмаштырырга;

- 6.11 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру һәм хокукый тәэмин итү максатларында Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары Иҗтимагый совет секретарена һәм әгъзаларына, эш төркемнәренә, Иҗтимагый совет комиссияләренә көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча утырышларга мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләгәндә һәм җыйганда, Иҗтимагый совет эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүматны “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм “Татмедиа” ААҖ филиалының Әгерҗе районы “Әгерҗе хәбәрләре” газетасында урнаштырганда ярдәм күрсәтә,».